ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕМДЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422728, Республика Татарстан, Высокогорский
район, с.Мемдель, ул. Кооперативная, 30

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘМДӘЛ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422728,Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мәмдәл авылы, Кооператив ур., 30

тел./факс 8(84365) 60-2-37, e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 август 2018ел № 14

**Биектау муниципаль районы
Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге территориясендә документларның
күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең
дөреслеген таныклау буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга

2. Мәмдәл авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 10 маенда кабул ителгән 5 нче номерлы муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турындагы карары белән расланган документларның һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә. http://pravo.tatarstan.ru/ - Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә

4. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә (халыкка җиткерелгәннән соң)

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Мәмдәл авыл җирлеге Ф.Г. Сафиуллин